ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 07.07.2023 **КАРАР**
933

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының махсуслаштырылган торак фонды составына торак урыннарны кертү һәм составтан чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 14 декабрендәге 1728 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2012 елның 27 февралендәге 149 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Электрон формада, дәүләт йөкләмәсе (заказы) урнаштырыла торган, Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрдән, социаль әһәмиятле дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә күчү чаралары планын раслау турында» 2021 елның 13 апрелендәге 242 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының махсуслаштырылган торак фонды составына торак урыннарны кертү һәм составтан чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 14 декабрендәге 1728 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Регламентның 1.1 пунктын түбәндәге эчтәлекле 1.1.3 пунктчасы белән тулыландырырга:

«1.1.3. Махсуслаштырылган торак фондының торак урыннарына (алга таба - махсуслаштырылган торак урыннары) түбәндәгеләр керә:

- хезмәт торак урыннары;
- тулай торак урыннары;
- маневр фондының торак урыннары;
- гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү системасы йортларында торак урыннары;
- мәҗбүри күченүчеләр дип танылган затларга вакытлыча яшәү өчен фонд бинасыннан торак урыннары;
- качаклар дип танылган затларга вакытлыча яшәү өчен фонд бинасыннан торак урыннары;
- гражданнарның аерым категорияләрен социаль яклау өчен торак урыннары;
- ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга һәм ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затлар өчен торак урыннары».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Р.Л. Исланов